### *Комиссия алынган җавапларның “дөреслеген”ә караганда, катнашучыларның “дәрәҗәсен һәм потенциалын” күбрәк бәяли...*

***(“Дәүләт хезмәткәре бүген” интервьюлар циклыннан)***

*Конкурслар һәм аттестация комиссияләре турында Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясенең бәйсез эксперты, доцент, ф.ф.к., “АБАДА” фәнни-интеграция берләшмәсенең фәнни-методологик тәэминат департаменты җитәкчесе Сафиуллин Ленар Касыйм улы сөйли*



***- Ленар Касыймович, хәерле көн! Министрлыкларның һәм ведомстволарның, шул исәптән Инспекциядәге комиссияләр эшендә Сез кайчаннан бирле бәйсез эксперт буларак катнашып киләсез? Шул хакта сөйләп үтегезче, зинһар өчен.***

- Комиссияләрдәге эш тәҗрибәм – 2002 елдан башлап, унөч ел (ТР Президенты Аппаратындагы вазыйфаи вәкаләтләр кысаларында). “Бәйсез эксперт” рәвешендәге эшем, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясендә, – җиде ел.

***- Конкурсларны һәм аттестацияләрне оештыру һәм үткәрүдә Сез нинди уңай күренешләрне билгеләп үтәр идегез һәм аларны әзерләгәндә, үткәргәндә һәм анда катнашканда нәрсәләргә игътибар итәргә кирәк?***

- Төп уңай моментларның берсе шул: конкурсларны һәм аттестацияләрне оештыру һәм үткәрү процессы “бер урында гына тормый”, ул гел үсештә, үзгәрешләр кичереп тора. Шул ук вакытта, минем карашка, оешма җитәкчелеге һәм комиссия әгъзалары ягыннан катнашучыларга карата гел позитив, уңай караш саклана. Әлбәттә, конкурсларны һәм аттестацияләүләрне оештыру һәм үткәрү – иҗади процесс һәм сораулар, аларны җиткерү формалары үзгәреп тора, чөнки конкурс процедураларын оештыруда һәм үткәрүдә күп нәрсә оешманың хәзерге вакытта нинди үсеш дәрәҗәсендә булуына, оешманың тулаем алганда үзалдына һәм һәр хезмәткәренә куелган бурычларына һәм төп максатларына, хәтта

җәмгыятьнең һәм дәүләтнең тулаем алгандагы торышына бәйле. Димәк, һәр яңа иҗтимагый этапта дәүләт хезмәткәрен бәяләү өчен иң мөһим булган сорауларның “кристаллашуы” барлыкка килә, мисал өчен, бүген – ул коррупциягә каршы тору мәсьәләләренә бәйле. Шулай ук бүген хезмәткәрләрнең шәхес сыйфатларына – аларның социаль активлыгына, оешманы үстерүдә (прогрессслауда) катнашу теләгенә дә зур игътибар бирелә. Шуңа күрә бүгенге конкурслар һәм аттестацияләүләр – “комиссия сорауларына җавап бирү” белән генә чикләнеп калмый, алга таба, тирәнгәрәк, хезмәткәрнең оешмада үсүенә бәйле нечкәлекләрне сөйләшү максаты белән профессиональ әңгәмә үткәрүгә, соңгы вакытта ул алган күнекмәләрне һәм белемнәрне, аның максатларын һәм планнарын ачыклауга юнәлдерелә.

***- Сез ничек уйлыйсыз, конкурс яисә аттестацияләү барышында дәүләт хезмәткәрләренә, Инспекция хезмәткәрләренә Сезнең тарафтан җиткерелгән кайбер сораулар ни өчен җавап бирүдә кыенлыклар тудыра?***

- Бәлки, кеше өч елга бер тапкыр гына мөрәҗәгать итә торган мәсьәләләргә бәйле сораулар шулай җавап биргәндә кыенлык тудыра торгандыр. Еш кына бу сораулар дәүләт хезмәтенә - тиешле законны, РФ һәм ТР Конституциясен белү-белмәүгә кагыла. Дәүләт хезмәткәрен дәүләт яллый һәм шуңа күрә бу дәүләтнең нидән гыйбарәт булуын, кая таба хәрәкәт итүен һ.б. белеп торырга кирәк.

Конкурсларда катнашуга бәйле кыенлыклар шулай ук еш кына әлеге конкурс процедураларын үткәрүнең максатларын һәм бурычларын дөрес аңламау бәласе дә: кемдер конкурсларны “имтихан”, комиссия сорауларына “дөрес” җавап бирергә кирәк булган процедура буларак кабул итә, югыйсә бу бик үк дөрес түгел – хәтта тиешле документларда да әлеге процедураларның “претендентларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләү, кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү” өчен үткәрелүе турында язылган. Комиссия алынган җавапларның “дөреслеген”ә караганда, катнашучыларның “дәрәҗәсен һәм потенциалын” күбрәк бәяли...

Моннан тыш, кайберәүләр өчен, үз-үзеңне тотрыклы тоту сыйфатын, ә иң яхшысы – үзеңнең хәтереңне һәм фикерләү сәләтеңне актив үстерүгә караганда, “мин дулкынланам” формулировкасына яшеренеп калу әлегә җиңелрәк …

***- Инспекциядәге комиссия эшендә катнашып Сез безнең белгечләрнең һөнәри үсешен күзәтә аласыз. Бу хакта ниләр сөйли аласыз? Сезнең карашка нәрсәләргә күбрәк игътибар юнәлтергә кирәк?***

- Һөнәри үсеш ул һөнәри компетентлыкны җәелдерүне, һөнәрнең үзенчәлекләренә тирәнрәк үтеп керүне, һөнәрнең даими үзенчәлекләрен үзләштерүне, әлеге һөнәргә ярашлы булган әһәмиятле процессларны һәм тагын да катлаулырак дәрәҗәле мәсьәләләрне хәл итә белүне күздә тота. Һәм бу җәһәттән хезмәткәрләр үзләрен бары тик яхшы яктан гына таныта – алар үүләренең махсус күнекмәләрен һәм белемнәрен, төзелеш өлкәсендәге квалификацияләрен даими арттырып торалар. Әмма шул ук вакытта “дәүләт хезмәте”нең шулай ук “һөнәр” булуын онытырга ярамый. Төзүченең, табибның, укытучының һ.б.ш. эше үзенә күрә үзенчәлекләре, принциплары, гореф-гадәтләре булган һөнәри эшчәнлек икәнен барысы да белә, ә дәүләт хезмәтенең шулай ук үз законнары һәм кодекслары (аларны белергә һәм хөрмәт итәргә кирәк) булган “һөнәри эшчәнлек” булуын күпләр күз уңыннан ычкындыра... Мисал өчен, СНиПлар барлык хезмәткәрләр тарафыннан да бик тә мөһим булган техник, икътисади һәм хокукый характерлы актлар буларак кабул ителә, аларны белмәгән хәлдә төзелеш эшчәнлеге иминлекле була алмый. Үзенең һөнәри карьерасы турында уйлаганда, дәүләт хезмәткәре дә конкурсларга һәм аттестацияләргә әзерләнгәндә мәҗбүри булган документларның – дәүләт граждан хезмәте турындагы тиешле законның, этика һәм хезмәттә үз-үзеңне тоту кодексының һ.б. үзара бәйләнешен әнә шулай аңларга тиеш.

***- Яшь дәүләт хезмәткәрләренә Сез нинди теләкләр җиткерер идегез?***

- Конкурс процедураларына имтиханга караган кебек түгел (чөнки имтиханнар, кагыйдә буларак, иң беренче чиратта нәтиҗә чыгаруга, тормыштагы теге яки бу этапны тәмамлауга юнәлдерелгән), ә продуктивлырак, һөнәрдә һәм шәхес буларак камиллеккә ирешүдә яңа этап башлау өчен шарт һәм мөмкинлек буларак, үзеңнең ялганганнарыңны күрсәтү өчен һәм алдагы үсешеңне билгеләү өчен мөмкинлек буларак карарга. Шуңа күрә әлеге процедураларга пассив булмаска (“чираттагы аттестациягә чакыру”ларын көтеп ятмаска), ә актив булырга, алар турында ешрак искә алырга, әлбәттә инде, конкурс яисә аттестация кысаларында комиссия тарафыннан уңай кабул ителердәй эшләрне башкарырга кирәк: илнең һәм республиканың иҗтимагый-сәяси тормышы белән кызыксынырга, даими рәвештә тиешле әдәбият һәм документларны укырга, квалификацияне арттырырга, кимчелекләреңнең тискәре йогынтысын киметергә, шәхес буларак потенциалыңны, стрессларга каршы торучанлыкны, аналитик фикерли алуны, планлаштыра, оештыру белүне һ.б. үстерергә.

***- Ленар Касыймович, рәхмәт, безнең өчен Сезнең фикерләрегезне белү бик мөһим иде. Ел саен август аенда төзүчеләр үзләренең һөнәри бәйрәмен – Төзүче көнен билгеләп үтә. Безнең коллегаларга нинди теләкләрегез бар?***

- Төзелеш тармагы – гел аеруча зур игътибар юнәлтелүче өлкә ул. Чөнки төзелештәге уңышлар – һәр кешенең, һәр гаиләнең, шулай ук республиканың һәм тулаем алганда илнең муллыгында төп шартларның берсе булып санала. Төзелеш тармагы – безнең җәмгыятькә икътисади һәм социаль мәсьәләләрне чишү өчен ныклы нигез булып тора.

Җәмгыятебез төзелеш өлкәсенә һәрчакта да аеруча зур игътибарлы булды: нәкъ менә төзелеш тармагындагы уңышлар күпләргә оптимизм хисен бирә һәм иртәгәсе тормыш турында ышаныч уята. Шуңа да Төзүче көне дигән һөнәри бәйрәм бу өлкәдә хезмәт куючылар өчен һәм республикадагы һәм илдәге барча халык өчен аеруча зур вакыйга булып тора.

Мин ышанам, сез үзегезнең һөнәри эшчәнлегегез кысаларында – хезмәт сөючәнлекне һәм максатка омтылучанлыкны, активлыкны һәм оешканлыкны, үзлектән үсүдә бердәм булу кебек иң яхшы сыйфатларыгызны гына чагылдырасыз. Шуңа күрә дә бүген бәйрәм көне, үткән елдагы эшегез күзгә күренерлек, уңышларыгыз сизелерлек һәм горурланырлык. Әйдәгез, төзелеш тармагы киләчәктә дә илебезгә һәм халкыбызга тагын да зуррак уңышлар китерсен өчен көчтән килгәннең барысын да эшлик!

Барлык төзүчеләргә дә ихтирам билгесен тапшырасым килә, сезне, туганнарыгызны һәм якыннарыгызны чын күңелдән котлап, ныклы сәламәтлек, рух көрлеге һәм яңа хезмәт уңышлары телим! Әлеге бәйрәм сезгә яңа өметләр, батырлыклар һәм уңышлар алып килсен!

---

Сафиуллин Ленар Касыйм улы, бүләкләре:

— “Казанның 1000 еллыгы истәлегенә” медале,
— “Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтен гамәлгә ашырудагы хезмәтләре өчен” алтын мактау билгесе,
— “Муниципаль идарә өлкәсендә иң яхшы хезмәткәр” республика конкурсында “Фәнни тикшеренүләр һәм кадрларны әзерләү” номинациясендә 2013 ел нәтиҗәләре буенча җиңүче дипломы.

***ТР ДТКИ матбугат хезмәте***